وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№3 (172). 18 гыйнвар 2013 / 6-рабыгыль-әүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Россиянең мөселман татарлары арасында Мәүлид бәйрәме: зәүкый аспект

▷ 2, 4 ◁



Мәүлид

▷3◁



"Исәнме-саумы, күршекәем!"

▷4◁

# Сөннәт

**Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган айда бөтен дөнья мөселманнары аның үрнәк тормыш юлы хакында уйлана, искә төшерә. "Сөннәт" сүзе гарәп теленнән "юл" дигән мәгънәне аңлата. Пәйгамбәребез (сгв) үткән юлның бер өлешен генә булса да кабатларга тырышып сөннәт гамәлләр башкаруыбыз белән, без сөекле Пәйгамбәребезне (сгв) безгә иң зур рәхмәте-мәрхәмәте буларак җибәргән Аллаһы Тәгаләгә якынаябыз.**




**Сөннәт - Шәригатьнең икенче чыганагы - Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән сүзләре һәм гамәлләре, ягъни хәдисләре. Хәдисләр бик күпләр өчен бу тормышта юл күрсәткеч, чөнки аларда бөек шәхес тормышы, Аллаһка ихластан ышану, инану ачыла. Әйтик, Сөннәт аша без зәһәрләнергә, усалланырга ярамаганлыгын беләбез, чөнки бу безнең гамәлләргә генә түгел, кеше сәламәтлегенә дә зарар китерә. Пөхтәлек, чисталык - иманның яртысы, дибез һәм шуңа күрә күп кенә авыруларның мөселманнарны читләтеп үтүен күрәбез. Пәйгамбәребез (сгв) сабыр булырга өйрәтә, чөнки сабырлык - иманнан. Тагын ул мөселманнарның саваплы эшләрдә үз гаиләләреннән, якыннарыннан, дусларыннан башлап бер-берсенә ярдәм итәргә тиешлеген әйтә.**

**Әгәр дә сөннәтне тирәнтен өйрәнә башласаң, бары бүгенге заманның гына атаклы психологлары үз хезмәтләрендә яза башлаган кешеләр арасындагы психологик мөнәсәбәтләр турында күп кенә нәрсәләрне белергә була. Шуларның берсен генә мисалга китерәбез: Дейл Карнеги елмаюның шактый проблемаларны чишә алуына ышанган. Ә Пәйгамбәребез (сгв) бу турыда 14 гасыр элек әйтеп калдырган. Шуңа күрә ихластан елмаю - сөннәт.**

**Коръәни-Кәрим һәм Сөннәт - мөселманнар өчен теләсә кайсы заманда әһәмияткә ия какшамас хаклык чыганагы. Сөннәт Кәрьәни-Кәримдә язылганны аңлата: нинди гамәлләр яхшы, ничек дога кылырга, тәһарәт алырга һ. б. Сөннәт - җентекләп язылган яшәү инструкциясе ул. Төп Сөннәтләрне барлык мөселманнар да белә һәм үти - сөннәт намазлары, тәһарәттәге сөннәтләр. Ә менә тирәнрәк сорауларга җавапларны гыйлемле кешедән - остаздан, имамнан, казыйдан сорарга кирәк. Гыйлемле кешеләргә мөрәҗәгать итү - шулай ук сөннәт.**

**Пәйгамбәребез (сгв) үткән юлын, хәдисләрен һәм аның күркәм сыйфатларын, шәхесен өйрәнүләр, бу хактагы уйланулар безне изге гамәлләр кылырга илһамландыра, күңелебезне, зиһенебезне баета.**


***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***


# Дүрт кагыйдә

**Әлхәмдүлилләәһи раббил галәмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн.**
**Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү, газиз дин кардәшләрем!**
**Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр, хәерле сәламәтлекләр биреп, гаиләләребездә бала кайгыхәсрәте күрмичә, әти-әниләребезнең догасын алырлык иттереп, матур, күркәм рәвештә яшәүләрне насыйп итсә иде.**




Пәйгамбәребез Мөхәммәдне (сгв) искә алганда һәркайсыбыз үз-үзенә сорау бирергә тиеш: ул бу Җиргә ни өчен килгән, Аллаһы Тәгалә аны ни өчен җибәргән?..

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Мин Җир йөзенә гүзәл әхлакны тәмам итеп урнаштыру өчен килдем", - ди. Мәүлидне зурлап, пәйгамбәребез Мөхәммәдне (сгв) искә алабыз икән, без һәрвакыт үзебезгә карарга тиеш: безнең әхлагыбыз нинди? Ул Пәйгамбәребез (сгв) әхлагына туры киләме?..

Ислам динендә ике генә фарыз бар: берсе - Аллаһны тану, икенчесе - гүзәл әхлак. Без намаз укыйбыз, ураза тотабыз, хаҗ кылабыз икән, ул безнең әхлагыбызда чагылыш табарга тиеш. Әгәр намаз укып та, син телең белән кешене рәнҗетәсең икән, син намаз укымыйсың, ә бәлки гимнастика гына ясыйсың булып чыга...

Ә гүзәл әхлакны урнаштыру өчен Пәйгамбәребезгә (сгв) Аллаһ Раббыбыз Коръән иңдергән, Пәйгамбәребез (сгв) аркылы безгә фарызларны җиткергән. Без фарызларны үтәргә, хәрамнардан тыелырга, Пәйгамбәребезнең (сгв) Сөннәтләрен үтәп яшәргә тиеш. Әхмәдһади Максудиның "Гыйбадәте Исламия" китабында: "Коръәндә барлыгы 6226 аять бар", - диелгән. Дини чыганакларда: "Барлыгы бер миллионга якын хәдис бар", - дип хәбәр ителә. Болар һәммәсе дә - хакыйкатьтә, дүрт кагыйдәгә сыеп бетә. "Коръән һәм хәдис буенча яшим", - дип йөрүче дә, гомумән, һәркайсыбыз: "Мин шушы кагыйдәләрне үтимме?" - дип, үз-үзенә сорау бирергә тиеш.

Әхлакның иң беренче кагыйдәсе - Аллаһы Тәгаләне һәм Ул яраткан бөтен нәрсәне ярату; Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылу һәм беркемне дә сүкмәү. Пәйгамбәребез (сгв) әйтте: "Мәрхәмәт кылган - мәрхәмәт кылыныр, сөйгән - сөелер, онытмаган - онытылмас". Икенче бер хәдисендә Мөхәммәд (сгв): "Аллаһы Тәгалә сезгә әниегезгә караганда да якын", - диде. Без Җир йөзендәге һәркемгә, һәр кешегә, һәр җан иясенә мәхәббәт күзе белән карарга һәм аны яратырга тиеш. (Урамда яткан исерек тә искәрмә була алмый. Кайчак бездә хатын-кызлар: "Ничек тәгәрәп ята иде, күрдеңме?!" - дип, авыл буенча шуны сөйләп йөри-

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАМАЛ ТЕАТРЫНДА – МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ

**28 гыйнвар көнне Г.Камал театрында Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көненә багышланган бәйрәм чарасы үтәчәк.** Мәүлид бәйрәмендә вәгазьләр сөйләнер, мөнәҗәтләр укылыр, дип көтелә. Әлеге чарада танылган дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре чыгыш ясаячак. Бу кичәне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте оештыра.

### КАЗЫЯТ УТЫРЫШЫ ҮТТЕ

**14 гыйнвар көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Казыйлар шурасы утырышы үтте**. Әлеге утырышта Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, республикабызның төбәк казыйлары катнашты. Җыелышта көньяк-көнчыгыш төбәгенә караган Ютазы, Лениногорск, Бөгелмә, Баулы мөхтәсибләре хисап тотты. Алар үзләренең мөхтәсибәтләрендә алып барылган дини эшчәнлек турында сөйләде.

Утырышта казыйлар 2013 елга намаз вакытлары, мәрхүмнәрне соңга юлга озату йолаларына кагылышлы сорауларны карады.

### КАБАН АРТЫ МӘЧЕТЕНДӘ ГАРӘП ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ ҮТӘ

**Исхак хәзрәт исемендәге Милләтара мәдәни-агарту үзәге Казанның Кабан арты мәчетендә һәр атнаның сишәмбе көнендә иртәнге сәгать уннан (10.00) көндезге бергә (13.00) кадәр өлкән яшьтәге хатын-кызлар өчен гарәп теле дәресләре уздыра.**

Шулай ук һәр пәнҗешәмбе рус телендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен "Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләренә аңлатма бирү" дип аталган темага лекцияләр укыла.

### МӘЧЕТ ТӨЗЕЛЕШЕ ДӘВАМ ИТӘ

**Түбән Камада яңа мәчет төзелеше дәвам итә.** Бүгенге көндә мәчетнең гөмбәзен эчке яктан тышлау эше төгәлләнде. Шулай ук манараны өеп менү тәмамланды. Аның биеклеге 30 метрдан да артып китте. Хәзерге вакытта манарага куелачак ай Чиләбедә әзерләнә. Шушы көннәрдә мәчет эчендә рәссамнәр үз эшләренә тотыначак.

*Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# Яратыгыз!

**Балалар белән булган әңгәмә вакытында: "Сезне әти-әниләрегез тез өстенә утыртып, кочагына алып сөяләрме?" - дип сорау сорау бирәм. Тынлык.**

Әкренләп куллар күтәрелә башлады. Аллага шөкер, балалар сөюдән мәхрүм түгел. "Рәхәтме соң, яраткач?!" Балаларның күзендә очкын, йөзләрендә - нур.

Әңгәмәбезне болай башлавымның сәбәбе бар: балалар ата-анадан читләшә башлады, назны тоймый үсәләр. Әти-әнине матди яктан тәэмин итеп тора торган саклык кассасы итеп күрүләре барыбызга да мәгълүм. Ата-ана баласы итагатьле булып үссен өчен, иң башта аңа күркәм исем кушарга, хәләл ризык ашатырга, гаиләдә хөрмәт, тынычлык булдырырга, дөньяви һәм дини гыйлем бирергә тиеш. Шушыларның бер генә шарты үтәлмәсә дә, дөрес тәрбия бирү мөмкинлеген кулдан ычкындырачакбыз.

Яшь гаиләләр әлеге мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү максатыннан, мәдрәсәгә "түгәрәк өстәл" янына җыелды. Өчәр-дүртешәр балаларын ияртеп килгән мөселман гаиләләре үзләре белән таныштыра барды. Югары Ушмадан килгән Төхфәтовларның әтисе сөйли: "Тормыш упкынына төшеп бара идем, шунда бабамның яшәеше күз алдыма килде. Энем дә мәчетләргә йөреп намазга басты. Аларның да тәэсире булгандыр, күңелемдә дә ниндидер якты нур калыкты. Бүгенге тормышым өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтлемен." Җәмәгатенә сорау бирәм: "Укытучы булгач, намазларны вакытында укый аласызмы?" "Ихлас булсаң, бөтен нәрсәгә дә өлгереп була", - дип җавап бирә ул.

Чәбьяледән Шамил Сәләхов җәмәгате Рауза ханым белән өч егет, ике кыз тәрбияли. Шамилнең дәгъвәт эшен яхшы алып барганын күптән беләбез, моның өстенә оста тәрбияче дә икән әле. Урта Кирмәннән алты бала атасы Фаил Нәгыймов дини йолаларны теләп һәм Аллаһ ризалыгы өчен дип башкара. Шушы ук авылдан Сөмбел Шәрифуллина өч энесенә өлкән апа буларак катнашты. Ул "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә һәм КФУда белем ала. Илһам, Наил, Илнур, Габдрахман, Айнур хәзрәтләр иң акыллы һәм иң сөйкемле кызларны үзләренә хәләл җефет итеп сайлаганнар. Кайберәүләр бер бала тәрбияләргә курыккан заманда алар өчәр-бишәр бала үстерә. Чөнки яхшы аңлыйлар: һәр бала дөньяга үз ризыгы белән туа. Яшь гаиләләр үзара фикер алышса, балалары туйганчы аралашты. Викторинада катнашып, бүләкләр алдылар. Комарлы уеннар уйнап, үзен дә, гаиләсен дә бәхетсезлеккә дучар иткән ата турында фильм карадылар. Әйе, тормыш чоңгылларыннан тартып алучы чын дуслар, рухи остазлар һәммәбезгә дә кирәк. "Түгәрәк өстәл"дә катнашучылар үзеңә генә түгел, сүнеп бара торган гаиләләргә дә ярдәм кулы сузып, зур савап алырга мөмкин икәнлеген яхшы аңлаганнар. Дини белемле мөгаллимнәрнең тирән эчтәлекле вәгазьләрен тыңлау үзе генә ни тора! Мәҗлес табын артында дәвам итте.

Авылларыбызда башкаларга үрнәк булып мөселманча гомер кичерә торган гаиләләр шактыйдыр. Кешеләр күңелендәге яңа фикерләрне, уйларны башкаларга җиткерергә әзер торучы гәҗитебез - "Дин вә мәгыйшәт" аша үзегезне белгертегез, күркәм тәҗрибәгез, файдалы киңәшләрегез белән уртаклашыгыз, дигән теләктә калам.

***Рәшидә Әүхадиева,***
***Мамадыш районы Урта Кирмән мәхәлләсе абыстае***

# 2013 ел: Кол Галинең тууына 830 ел тула

**Быел данлыклы татар шагыйре һәм дин эшлеклесе Кол Галинең тууына 830 ел тулачак. Урта гасырларда яшәгән атаклы каләм ияләренең күбесе, шул исәптән төрек шагыйре Хәмзә һәм үзбәк каләм иясе Дүрбәк тә, Кол Галине үзләренең остазлары дип санаган. Гарәп имлясында борынгы төрки әдәби телдә иҗат ителгән поэма татар әдәбиятының дини әсәрләр белән тыгыз бәйләнештә торуының күркәм бер мисалы булып тора. Үткән гасырларда һәм бүгенге көндә дә татар язучыларының күбесе үзләренең иҗат җимешләрен Коръәнгә һәм аның эчтәлегенә салынган кыйммәтләр белән бәйләп яза.**

Дин һәм әдәбият бигрәк тә татарларда аерылгысыз санала. Борынгы заманнарда яшәгән кайсы гына имамны алып карасаң да, ул шигырь язу белән мавыккан, ә һәр каләм иясе - мулла булган. Болгар мулласының гүзәл әсәре - "Кыйсса-и Йосыф" - Коръәндәге Йосыф һәм аның унике туганы турында хикәятнең сәнгати чагылышы.



Поэманың авторлык кульязма нөсхәсе безнең көннәргә кадәр сакланмаган, әмма бу әсәрнең күпсанлы күчермәләре килеп җиткән. Йосыф турындагы поэманың сюжеты Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләрендә дә билгеле. Кол Гали поэмасының нык таралуында, ихтимал, әлеге үзенчәлекнең йогынтысы да чагылыш таба. Әсәрнең төп идеясе - гадел җәмгыять төзергә омтылыш, үзара ызгыш-талашны, таркаулыкны бетерү, тынычлыкка өндәүдән гыйбарәт. Бу китап монголлар явы килгән чорда иҗат ителгән һәм таралган.

Поэма озак еллар буе халкыбызның күңел түрен биләп торган. XIX гасырга чаклы бу китап кияүгә чыгучы милләтебез кызларының бирнәләрендә алыштыргысыз әйбер булып саналган. Нәкъ менә шуңа карап алар үзләренең әхлакый кыйбласына тугры калып, кечерәк яшьтәгеләр үзләренә үрнәк итеп Йосыфны, өлкәнрәкләр исә аның атасын Ягъкубны алганнар.

2010 елда поэма Татарстан хөкүмәте ярдәме белән инглиз теленә тәрҗемә ителде һәм чит ил укучысына да иреште. Кол Гали Шәрыкның Хафиз, Низами Гәнҗәви, Галишир Нәваи, Гомәр Хәййам, Шота Руставели кебек атаклы шигърият осталары белән беррәттән үзенең лаеклы урынын алды...

***Рәсемдә: рәссам Р.Шәмсетдиновның "Кыйсса-и Йосыф" поэмасына багышланган иллюстрациясе.***

***Сөләйман әл-Казани***
***Чыганак: www.islam-today.ru***

# Россиянең мөселман татарлары арасында Мәүлид бәйрәме: *ЗӘҮКЫЙ АСПЕКТ*

**Россия мөселманнарының Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен (Мәүлид бәйрәмен) билгеләп үтүләренең әдәби алымнары өйрәнелгән-тикшерелгән бу күренештә халыкның эстетик идеалларын формалаштыра торган билгеле бер сәнгать стиле барлыгы дәлилләнә.**

Мәүлиднең сәнгатьчә үзенчәлекләренең берсе - аның композициясе (текст төзү системасы). Мәүлидне төрлечә бәян итүчеләрнең чагыштырма анализларында аның өчен гомуми булган кануннарны билгеләргә мөмкин: 1) кереш өлеш; 2) төп өлеш; 3) йомгаклау. Бәян итүнең һәр кисәге бер темага багышланган була, аны билгеләү әлеге кисәктә Мәүлид бәйрәме эчтәлеге төзелешен җентекле тикшерү мәсьәләсенә карый. Кисәкләрнең күләмен һәм сәнгатьчә тасвирлауларны үзгәртү - чагылдырылган теманың характерына бәйле. Мәүлидтә чагылыш алган темалар даирәсе никадәр күптөрле, уку процессына кертелгән текстның күләме никадәр зур яки кечкенә булмасын, бәян итү барышы һәрвакыт, мәҗбүри рәвештә, кереш өлеш, төп өлеш, йомгаклау элементларының эзлеклелеген үз эченә ала. Композиция элементлары бер-берсе белән нык, органик рәвештә бәйләнгәннәр, алар Мәүлид драматургиясенең билгеле максатына ирешүнең мәгънәви чылбырын тәшкил итәләр. Тулысынча алганда, композициянең өч өлешле бу структурасы антик чордагы гимн язуны искә төшерә. Мәүлид бәйрәме композициясе дә гомум кабул ителгән "Бисмилла" белән башланып китә һәм аннан соң "Каршы алу догасы" белән дәвам иттерелә. Ул гарәп телендә, проза белән укыла. "Каршы алу догасы"н Мәүлидне башкару өчен махсус чакырып алынган кеше укый. Бу кеше Мәүлиднең төп "режиссёры", "либреттисты" һәм төп башкаручысы да. Ул бәйрәм тәмамланганчы аның барышы белән җитәкчелек итә. "Каршы алу догасы"н укыган вакытта, бәйрәмгә чакырылучыларның уч төпләре "күктән иман нурын җыяр өчен", бер-берләренә якынайтып, өскә таба күтәрелгән хәлдә була. "Каршы алу догасы"н башкаручы көйләп укый, катнашучылар аны кайвакыт кычкырып "Амин" дип әйтеп, кайвакыт эчтән кабатлыйлар. "Дога"ның йомгаклау өлешен укыган вакытта татар теленә күчәләр. Бу вакытта, доганы укучы, гарәпчә өлешендә мелодияләнгән интонацияне саклап калып, көйләүне тизләтә. Көйләүнең бу вакыттагы төп интонацияләре - Коръәнне көйләп уку өчен хас булган интонацияләр. Татар теленә күчү - "Дога"ның бетә баруын аңлата. Тавышның көчәя баруы, шигъри сөйләмнең мелодик интонацияләре, диапазоннары арту да шул турыда хәбәр итә. "Кабул итү догасы"н катнашучылар "Амин" сүзе әйтеп төгәллиләр, аннан соң "илаһи иман нурын" үз йөзләренә учлары белән "сирпиләр". "Дога"ның мәгънәсе - Аллаһка мөрәҗәгать итү, Аннан җыелу ниятенең һәм урынының хәер-фатихалы булуын раславын, ризалыгын сорыйлар. Бу сүзләрдән соң дөньяви темаларга сөйләшүләр туктатыла, чөнки андый сөйләшүләр бу изге җыелышны башкаруга комачаулый дип исәпләнелә. Җыелышта бар катнашучылар да аның "режиссёры" (мулла яки абыстай) җитәкчелегендә бу гамәлдә катнашалар, аның тамашачылары да булалар. "Башкаручы" Коръән укый башлый. Бу очракта вакыйгаларны башкару турында мәгълүмат бирүчеләрнең барысы да бер фикердә, алар Коръәннең тәүхид нигезләнгән "Фатиха" исемле беренче сүрәсе укылырга тиешле дип исәплиләр. "Башкаручы" бу сүрәне берүзе генә көйләп укый. Башкаручылар, гадәттә, сүрәләрне укуның берничә төрле мәкамнәрен белә. Әгәр дә алар "Фатиха" сүрәсен билгеле бер мәкамдә укысалар, ә икенче сүрәне инде, гадәттә, икенче мәкамдә укырга тырышалар. Мәкамнәр уку темпы һәм көй ладлары төзелеше буенча бер-берсеннән аерылып тора. Мәүлид композициясе башында Коръән сүрәләрен уку - мәҗбүри. Мәкам һәм сүрәләрне сайлап алу "башкаручының" ихтыярына бәйле. Коръән сүрәләренә музыкаль интонацияләр бирүдә тәңгәллекне табу мөмкин түгел. Коръән сүрәләрен укыганнан соң, бәйрәмнең алга таба барышында күп төрле вариантлар булырга мөмкин. Республикабыздагы Тукай районының Абдул авылында бу урында артык кычкырмый гына Аллаһ исемен телгә алып, зекер әйтеп, дисбе тарта башлыйлар. Җаекта (Казакъстан Республикасы) Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) турында тарихи сәхифәләр укыла башлый, аның шәҗәрәсеннән егерме буын санап кителә. Шул ук вакытта аның ата-аналары, әхлак сыйфатлары, тормыш эшчәнлеге, вафаты турындагы белешмәләр дә китерелә. Барысы да "башкаручының" сәләтенә бәйле, ул һәрвакыт тыңлаучыларының кәефләрен искә ала белергә тиеш. Шулай итеп, композициянең кереш өлеше, гадәттә, Аллаһка мөрәҗәгатьтән, Аны данлаудан, пәйгамбәребез Мөхәммәдне (сгв) мактаудан, Аллаһ Рәсүленең (сгв) туган аен мактаудан тора.




Төп өлеш дип билгеләнгән өлеш - Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), аның кылган гамәлләре, аның белән бәйле вакыйгалар турындагы риваятьләр. Ул, гадәттә, Сөләйман Чәләбинең (1442 елда вафат) "Вәсиләтен-нәҗат" (ул башкача "Мәүлид ән-Нәби" исеме астында да билгеле) поэмасы өлешләрен укудан тора. Тик ул укулар "башкаручыларның" зур эшкәртелүендә укыла. Башкарылу барышында эчтәлекне ачып җибәрү ролен үзенә алган бу урта өлеш респонсорийны (аерым яки берничә җырлаучыга кумәкләшеп җырлап җавап бирүне) хәтерләтә. Шигъри көйләү җырлаучының көйләве һәм кумәк кабатлаулар белән чиратлаша.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*




# МӘҮЛИД

**Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне халкыбызда яратып үткәрелә. Пәйгамбәребезнең (сгв) вафат булган көне (Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көне) - аның туган көне буларак та олылап искә алына.**

Мәүлид кичәсе - бик күңелле, күркәм тантана. Ул бер генә көндә үткәрелми, ә бәлки ай буе дәвам итә. Рабигыль-әүвәл ае - Мәүлид ае. Димәк, тантана бу айның беренче көннәреннән үк башлана. Менә шул Мәүлид ае кергәч, кешеләр үзләренең теләгенә карап, хәлләреннән килгәнчә туганнарын, якыннарын, якын-тирәдәге карт-корыны, күршеләрне, яшь-җилкенчәкләрне табынга җыя. Мәүлид ае тәмамланганчы шул рәвешчә, бер-берсенә кунакка йөрешеп, Мәүлид укыйлар. Җомга көннәрне исә Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) турында вәгазьләр сөйләнә. Мәүлид кичәсендә мәчетләрдә Пәйгамбәребезгә (сгв) багышлап Коръәннән сүрәләр укыла, сәдака өләшенә.

Мәүлид кичәсендә нинди дини йолалар үткәрү шарт соң? Бу гади рәвештә генә кунак җыю түгел. Чакырылучылар арасында догалар укый белгән кеше булырга тиеш. Алар күп санда булса, тагын да яхшырак. Табын өстәленә җыелышып утыргач (әлбәттә, барысы да тәһарәтле, хатын-кызлар яулыктан, ирләр түбәтәйдән булырга тиеш), дин әһеле "Мәүлид ән-нәби" касыйдәсен (мактап язган шигырьләр) укый башлый, аннан соң Пәйгамбәребез (сгв) тормышында булган могҗизалар, кызыклы вакыйгалар турында сөйләнә. Башлап укыган кеше бераздан: "Салават" әйтик", - дигәч, табында утыручылар күмәкләшеп "Салават" әйтә. "Салават" әйтү тәмамлангач, табын догалары укыла һәм аш-су белән авыз итеп алына. Бәйрәм ахырында (хуҗаның теләге карап) хәер-сәдака таратыла, әмма ул мәҗбүри түгел. Чөнки табын сые үзе үк олы сәдакадан санала. Ахырзаман Пәйгамбәре - Мөхәммәдкә (сгв) атап дога кылына һәм Коръәннән аятьләр укыла, мөнәҗәтләр әйтелә.

Мәүлид мәҗлесләрендә "Әхзаб (Төркем)" сүрәсенең 38-48 нче аятьләрен ("Мәкәнә") уку бик тә савапы.

"Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Мәә кәәнә гәләәннәбиййии мин хәрәҗиң фиимәә фәрадалааһу ләһү сүннәтәллааһи фии-лләзиинә халәү миң каблү үә кәәнә әмру-ллааһи кадәрам макдүүраа. Әлләзиинә йүбәллигуунә рисәәләәти-лләәһи үә йәхъшәүнәһү үә ләә йәхшәүнә әхәдән илләллааһә үә кәфәә билләәһи хәсибәә. Мәә кәәнә Мүхәммәдүнә әбәә әхәдиммирриҗәәликүм үә ләәкиррасүүлә-хатәмән-нәбиййиин. Йәә әййүһәә-лләзиинә әәмәнүз-күруллааһә зикраң кәсиираа. Үә сәббихүүһү бүкратәү-үә әсыйләә. Һүүәлләзии йүсаллии гәләйкүм үә мәләә'икәтүһүү лийүхриҗәкүм минәззулүмәәти иләәннүүри үә кәәнә билмүьминиинә рахиимәә. Тәхиййәтүһүм йәүмә йәлкаунәһүү сәләәм. Үә әгәддә ләһүм әҗраң кәриимәә. Йәә әййүһәәннәбиййү иннәә әрсәлнәәкә шәәһидәүү үә мүбәшшираү үә нәзииραа. Үә бәшширилмүьминиинә би'әннә ләһүм минәллааһи фадләң кәбииραа. Үә ләә түтыйгил-кәәффириинә үәлмүнәәфик-ыйнә үә дәг әзәәһүм үәтәүәккәл гәләә-ллааһи үә кәфәә билләәһи үәкииләә".

Мәгънәсе (Р.Батулланың "Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре" китабыннан): 38) Аллаһ хәләл кылган нәрсәне башкарганнан Пәйгамбәргә гөнаһ юктыр. Элек яшәп китүчеләр (пәйгамбәрләр) дә Аллаһ хәләл кылганны гына башкаралар иде. Аллаһның әмерләре, һичшиксез, җиренә җиткезелә, алар (Ләүхел Мәхфүзгә) язып куелган тәкъдирдер. 39) Ул пәйгамбәрләр - Аллаһ иңдергән әмерләрне (кешеләргә) ирештерүчеләр, Аллаһтан куркучылар, Аннан башка беркемнән дә курыкмаучылар. (Хәттин ашканнардан) исәп-хисап алыр өчен бер Аллаһ Үзе җитәр. 40) Мөхәммәд сезнең арагыздагы бер генә ирнең дә атасы түгел. Ул фәкать Аллаһның Рәсүле һәм пәйгамбәрләрнең соңгысыдыр. Аллаһ һәрнәрсәне асылыннан белеп тора. 41) Әй, иманлы халык, Аллаһны һәрвакыт искә алыгыз. 42) Һәм Аны иртә-кич (мактап) тәсбих тартыгыз. 43) Сезне караңгылыктан (наданлыктан, динсезлектән) яктылыкка чыгармак өчен рәхмәтен вә мәрхәмәтен һәм фәрештәләрен күндергән - Улдыр. Аллаһ мөэминнәргә чиксез мәрхәмәтле. 44) Аллаһ белән кавышкан Көнне аларга эндәшү "Сәлам!" сүзе булыр. Аллаһ алар өчен бик тә мәртәбәле бүләкләр хәзерләде. 45) Әй, Пәйгамбәр, Без сине, чыннан да, шаһит, сөенче алучы вә кисәтүче буларак күндердек. 46) Аллаһның фатихасы илә (тугры юлга) чакыручы, нур чәчүче бер кандил сыйфатында күндердек. 47) Мөселманнардан сөенче ал: алар Аллаһның бөек Сәгадәтенә ирешәчәкләр. 48) Кяферләргә, монафикъларга баш имә. Аларның кысуларына дикъкать итмә, түз. Аллаһка инан, иманыңа таян. Химаяче буларак та, таяныч буларак та Аллаһ сиңа җитәр.

## "Якупов укулары"

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте узган елның 4 сентябрендә I Якупов укуларын уздырган иде. Шушы көннәрдә әлеге фәнни-гамәли конференциянең материаллары дөнья күрде. Ул 2012 елның 19 июлендә фаҗигале төстә арабыздан киткән мәртәбәле дин әһеле Вәлиулла хәзрәт Якуповның якты истәлегенә багышлана, анда I Якупов укуларында ясалган чыгышлар урын алган. Җыентыкка шулай ук Вәлиулла хәзрәтнең үзенең дә Татарстан мөселманнары өммәтендәге проблемаларга, мәшһүр татар дин әһелләренә кагылышлы мәкаләләре бирелгән. Шулай ук аның тормыш юлына кагылышлы мәгълүматлар, шәхси архивыннан фотолар куелган.***




Җыентык Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизнең Вәлиулла хәзрәт турындагы сүзләре белән башланып китә. "Вәлиулла хәзрәт республикабызда ислам дине үсешенә үзеннән олпат өлеш кертте. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе бинасы өчен көрәшеп йөрүен, Апанай мәчете, "Касыймия" мәдрәсәләрен өммәтебезгә кайтаруын гына алсак та, йөрәге-җаны белән дин, милләт, тел өчен янып яшәгәнлегенә төшенәбез. Шулар өстенә Вәлиулла хәзрәт дистәләгән китап авторы - үз заманының дини агартучысы булды. Аның җитәкчелегендә меңнән артык китап нәшер ителде. Вәлиулла хәзрәтнең хезмәтләренең кыйммәтен ачуда, аның юлын дәвам иттерүдә "Якупов укулары" бер адым булып торыр, дип ихластан ышанасы килә", - диелә Илдус хәзрәтнең конференция уңаеннан ясалган мөрәҗәгатендә.

# Дүрт кагыйдә

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

ләр. Хакыйкатьтә, болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең күргәзмә әсбабы. Менә шундый кешеләр аркылы Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да аракының нинди начар нәрсә икәнен күрсәтә. Беркемгә дә сер түгел: гайбәт сөйләгән кешене кайчак чәйнәп өзәсе килә башлый. Ә чынлыкта без исерек яныннан нәфрәтләнеп китәбез дә, шуның гайбәтен сөйләргә тотынабыз. Исерекне сөйләп-сүгеп йөргән кеше үзе үк, кибеткә кергәч хәләл акчасына аракы сатып ала да, аны өенә алып кайтып куя. Хакыйкатьтә, исерек һәм гайбәт сөйләүчеләр һәрберебездә дә исерткечкә һәм гайбәткә булган нәфрәт хисе уятырга тиеш. Локман Хәким дә: "Әхлаксыз кешене карап-күзәтеп әхлагымны төзәттем", - дигән. Менә шуңа күрә безгә әхлагыбызны үзгәртү, беркемне дә сүкмәү, һәр бәндәгә мәхәббәт күзе белән карау лазем. Кемдер ярамаган берәр нәрсә эшли икән, без шуннан гыйбрәт алып үзебезнең әхлагыбызны төзәтергә һәм шул кеше өчен: "Я Раббым! Бу бәндәңә тәүфыйк-һидаять бир", - дип дога кылырга тиеш.) Коръәни-Кәримдә болай диелә: "Яманнан тәүбәгә килеп, иман китереп, игелек кылганнарның яманлыкларын игелеккә алмаштырыр (кылган гөнаһларын ярлыкап, саваплы эшкә күндерер). Аллаһ ярлыкаучы, бик тә мәрхәмәтле" ("Фуркан (Яхшыны яманнан аера торган Китап)" сүрәсенең 70 нче аяте). Кем дә кем тәүбәгә килеп, изге гамәлләр кыла башлаган икән, аның әүвәлге гөнаһлары юкка чыгачак.

Икенче кагыйдә - Аллаһы Тәгаләнең бер мәхлукатына да зыян салмау. Без бер генә нәрсәгә дә зарар китерергә тиеш түгел. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән: "Мөэмин шул: кешеләр аннан үзләре һәм үзләренең маллары белән бәйле рәвештә үз-үзләрен кайгы-хәсрәттән имин дип хис итәрләр". Мөэмин, иман, иминлек - тамырдаш сүзләр. "Теленә, диненә, тән төсенә, милләтенә карамастан, мөэминнән бүтән кешеләр иминлек табар", - дигән (сгв). Мөселман кем дигәндә, мөселман шул: "Аның кулыннан да, теленнән дә башкалар сәламәт булыр", - дип әйткән Пәйгамбәребез (сгв). Хәдистә башка мөселманнарга карата гына иминлек күрсәтү турында сүз бармый, ә бәлки: "Теленә, диненә, тән төсенә, милләтенә карамастан, һәркем мөселман кешесеннән исән-имин булыр", - диелгән. Ислам, сәламәтлек, сәлам, мөселман сүзләре тынычлык дигән сүздән ясалган.

Өченче кагыйдә - Аллаһы Тәгалә биргәнгә шөкрана кылу. Әгәр дә моннан ун/егерме/утыз ел элек булган тарихыбызга карап: "Кайчан әйбәтрәк иде?" - дип сорасалар, һич икеләнмичә: "Бүген", - дип җавап бирәчәкбез. Шулай булмый ни: торган өйләрне, йөргән машиналарны, кигән киемнәрне, ашаган ризыкларны моннан утыз ел элек булганы белән чагыштырырлык та түгел. Ә кайчан күбрәк зарлана башладык?! Билгеле, бөтенебез дә: "Бүген", - дип әйтәчәк. Авызыбыз өч кенә төрле эш эшли: я зарланабыз, я гайбәт сөйлибез, я ашыйбыз. "Ибраһим" сүрәсенең 7 нче аятенә мөрәҗәгать итик: "Исегездәме, Раббыгыз сезгә: "Шөкер итсәгез, әлбәттә, сезгә (нигъмәтне) арттырачакмын, әгәр дә көферлек кылсагыз, һичшиксез, бирәчәк җәзам бик тә хәтәрдер", - дип хәбәр итте". Мин узган гасырның җитмешенче елларында гарәп хәрефләрен өйрәндем, Коръән укый башладым. Бу - комсомолга кергән еллар иде, моның өчен бераз шелтәләп тә алдылар. "Нишлисең? Ялгышасың бит!" - дип әйттеләр. Менә шул вакытта - Октябрь революциясенә бер көн кала: "Җәлил космоска менә, Марска оча", - дип әйтсәләр, бөтен кеше ышаныр иде. Ә без комсомолга кергән шул елларда: "Җәлил Татарстан президенты белән янәшә басып гает намазы укыр, ә аның ярдәмчесе чалган корбаннар белән авыз ачар", - дисәләр, акылга җиңеләйгән диюләре бик мөмкин иде... Аллага шөкер, динебез чәчәк аткан көннәрне дә күрергә туры килде. Нинди зур сөенеч: 2012 елда Мәүлид бәйрәмен үткәргәндә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Аллаһы Тәгалә алга таба да ил-көннәребезгә иминлекләр биреп, Президентыбызга үзе планлаштырган изге эшләрен башкарып чыгарга насыйп итсә иде. Безгә зарланудан туктап, шөкрана кылырга вакыт җитте. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Әмирләрегезнең һәркайсына буйсыныгыз, һәр имамның артында торыгыз, хәтта шайтанны да сүкмәгез", - дип әйткән. Бер кеше ташка сөртенгәч: "Ах, шайтан монда таш куйган икән!" - дип, шайтанны сүгә, ә аты сөртенгәч: "Ах, карт алаша, шул ташны да күрмисеңмени?" - дип, атын кыйный икән... Шуңа күрә шайтанның гаебе юк, чөнки шайтан Аллаһы Тәгалә кушмаган эшне эшләми. Аллаһы Тәгалә шайтанга: "Мин Коръән иңдерермен, пәйгамбәрләр җибәрермен. Коръәнне үтәгән, Пәйгамбәрнең (сгв) Сөннәтенә ияргән кешеләрне аздыру өчен синең көчең җитмәс", - диде. Кемдер шайтан вәсвәсәсенә бирелгән икән, монда кем гаепле? Билгеле, гаеп ул кешенең үзендә. Монда шайтанның катнашы юк. Шуңа күрә гаепне үзебездән эзләргә, беркемне дә сүкмәскә, зарланмаска кирәк. Пәйгамбәребез (сгв) хәдисендә болай диелә: "Кешегә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешү һәм ул кешенең галимлеге шуннан беленер: ул үзендә булган хата-кимчелекләрне күрә башлар". Шулай булгач, кемнәрнеңдер гаеп-кимчелеген күрү өчен зур галим булу кирәк түгел, аңа наданлык та җитә. Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв): "Берәү үзендә булган берәр кимчелекне бетерсә, һиҗрәт кылган савап алыр", - дигән.

Дүртенче кагыйдә - кирәкмәгән җиргә кысылмау. Руслар да әйтә бит: "Не суйтесь туда, куда не надо!" Кешегә ярдәм итәсең, киңәш бирәсең, кемне дә булса өйрәтәсең килсә, бу гамәлне акылыңны эшкә җигеп, аның рөхсәте белән генә башкарырга кирәк. Хуҗа Баһаветдин хәзрәтләре: "Сез иң элек кешеләргә ничек итеп өйрәтергә кирәк икәнлеген аңлатыгыз, чөнки берәү дә үзен өйрәткәнне яратмый", - дигән. Шулай итеп, ярдәм итәргә телисең икән, рөхсәт сорап, җайлап кына ярдәм итәргә, ярдәмне дә акыл белән эшләргә кирәк. Бер кеше аю белән дуслашкан. Бервакыт болар бергәләшеп юлга чыкканнар. Ял итәргә туктагач, аю кешене саклап торган. Кешенең битенә чебен кунгач, моның йокысы качмасын дип, аю тегеңә күсәк белән суккан. Шуннан соң кеше үлеп киткән. Әйтәсе килгән сүзем шул: ярдәмебез аюныкы төсле булмаса иде. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләнең һәр мәхлукатын яратыйк, берәүдән дә зарланмыйк, булганына шөкер итик. Кешеләргә киңәш биргәндә дә акыллы киңәшләребезне генә бирик. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да хәерле гомерләр насыйп кылса иде.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,
Татарстанның баш казые,
Балтач районы имам-мөхтәсибе**

# Россиянең мөселман татарлары арасында

# Мәүлид бәйрәме: ЗӘҮКЫЙ АСПЕКТ

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Респонсорийның тексты салаватлардан тора, алар җәелдерелгән катлаулы көйгә күмәкләшеп башкарылалар. Әгәр дә татарларның борынгы бабаларының бер өлеше - төрки болгар бабаларыбыз V гасырга кадәр көньяк-көнчыгыш Европада яшәгәннәрен һәм византиялеләр белән союздаш мөнәсәбәтләрдә булганнарын, Казан ханлыгының Византия империясенең варисы булган Госман империясе белән озак вакытлар булган бәйләнешләрен искә төшергәндә, бер яктан, борынгы Византия шигъри көйләү сәнгате кайтавазлары Мәүлид уку сәнгате үсешенә читләтеп йогынты ясый алганнар дип тулысынча фараз итәргә була. Ә икенче яктан, эпик әсәрләр - дастаннарны уку традициясе, һичшиксез, йогынты ясамый калмаган.

Күпчелек очракта икенче кисәк сюжетны ачып җибәрү "Үсмер турында хикәя"не уку белән башланып китә. Бу үсмер Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көненә зур хөрмәт күрсәтүе белән җәннәттә үзенә урын алуга ирешкән булган. Бу хикәяне укыганнан соң, салават әйтелә, Пәйгамбәребезгә (сгв) мактаулар яудырыла. Салаватны бар катнашучылары да бергәләп, бертавыштан әйтәләр. Ул гарәп телендә, мелодиядә әйтелә, өч тапкыр кабатлана. Төрле төбәкләрдә салаватлар мәгънәсе һәм мелодияләре белән төрлечә вариацияләрдә булырга мөмкин. Салават әйтелгәннән соң, Мәүлид укучы катнашучыларны Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен бәйрәм итәргә чакырган өлешенә күчә. Аннан соң тәүхид расланган бүлеккә күчелә. Бүлекләр һәрвакытта, кабатлана торган, билгеле бер көйгә яңгыраган, бертавыштан әйтелгән салаватлар белән үзара бүленәләр. Сюжет сызыгының Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууы белән сугарылган булуы бу вакыйгада катнашучыларны гел киеренкелектә тота.

Туу моментында укучы һәм катнашучылар урыннарыннан торалар һәм кечкенә Мөхәммәдне - Аллаһның сайлап алынганын (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) "Мәрхәбә!" дип (Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууын гимн кебек данлау) тәбрикләләр. Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) олылау соклану хисе, күңел күтәренкелеге белән яңгырый. Әгәр дә "Мәрхәбә!" алдагы көйгә әйтелә икән, бу көй әкренәйтелә. Яңгыраш - тантаналы, күтәренке. "Мәрхәбә" әйтелгәннән соң, барысы да кире үз урыннарына утыралар. Аннан соң Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туганнан соң булган вакыйгалар, аның тышкы кыяфәте, әхлак сыйфатлары, гамәлләре турында бәян итүләр дәвам иттерелә. Мәүлид уку Коръәннең беренче сүрәсе - "Фатиха"ны уку белән йомгаклана.

Шигъри өлешне укудан соң "Багышлау" башланып китә. Бу вакытта катнашучылар Аллаһка ялвaралар. Бу өлешне әсәрнең тын кульминациясе дип исәпләргә була, бу вакытта катарсис халәте күзәтелә. Татарларда Мәүлид уку сәнгате - ул дини нигездәге, үзенең эчке драматургия законнарына ия булган, синкретик музыкаль-шигъри сәнгать. Татар Мәүлидендә "сәхнә мәйданчыгы", сүзләр, көйләр, мизансценалар, ишарәләр, тойгылар даирәсе, гамәлләр, атрибутлар (дисбеләр, тәңкәләр, ризыклар һ.б.), "башкаручы-режиссёр", җыелышта катнашучылар куя торган алдан язылган "Мәүлид китабы" әсәре кебек, - театр элементлары бар. "Мәүлидне" бәян итүче өчен тыңлаучылар (алар, шулай ук, бәйрәмдә катнашучылар да), - тормыш кебек зарур даирә, алардан башка укучының үзенчә аңлау-аңлатуы илһамлы халәттә булмый. Ул публикага мохтаҗ. Аудитория кайвакыт бәйрәмдә катнашу һәм андагы рольләрне башкару белән мәшгуль булырга мөмкин, алып баручының сүз һәм гамәлләренә, Мәүлид бәйрәмендә ни дәрәҗәдә катнашуына (җыелыш алдыннан тәһарәт алу, җыелыш өчен бәйрәмчә киенү, каршы алу догасы, бергәләп хуплап әйтүләр, дисбе тартулар, зекер әйтү, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган моментта торып басу, күмәкләшеп катнашып китүләр, сәдака тарату, тәгамнарны илаһилаштыру, тәгам кабул итү, һәрберсенең дә музыкаль-шигъри кодында катнаша алу мөмкинлеге, бәхилләшү догасы һ. б.) бәйле рәвештә, төрлечә җавап бирергә мөмкин. Бәйрәм җыелышына әзерләнү, катнашучыларның күтәренке күңеле, уңышлы күмәк иҗади эш барышына ләззәт хисе өсти. Әсәрнең комплекслы сәнгать чаралары максатчан һәм стилистик берлеккә ия. Игътибарның чиксез тупланышы, катнашучыларны хисси халәткә кертеп чумдыру, катнашучыларның аңын әкренләп һәм ныклап үз кулыңа алу, көйләүләр үлчәме һәм ритмының драматургиясе белән берләшүе - бәйрәмдә катнашучыларны, психик халәтнең бик югары киеренкелегенә кадәр китереп җиткерә.

Һәр катнашучының күңелендә яраткан көйләү чалымнары бар. "Мәүлид китабы"-ның көйләү нигезләре мелодияләре бер башкаручыдан икенчесенә, авыздан авызга тапшырылалар, шуның белән ул халык авыз иҗатына якын тора. Татарлардагы "Мәүлид ән-Нәби" - ул халыкның иҗат җимеше. "Мәүлид"не башкаруда бер тапкыр катнашкан кеше коллектив иҗаттан, анда алган тирән тәэссоратларны бер вакытта да онытa алмаячак. Күргән, ишеткән һәм хисси тәэсссоратлар хәтердә зур һәм ныклы инану көченә ия булган бердәм сәнгать образы калдыра. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен бәйрәм итү процессының төп гәүдәләндерә торган хис даирәсе, беренче чиратта, бара торган вакыйганың мәгънәсе һәм бар текстны да укудагы музыкаль мөмкинлекләргә бәйле. Уку процессы ябык бүлмәдә алып барыла, ә бу аңа камералылык характеры бирә. Татарларда өй ярымфункциональ бина булган, ул берьюлы хуҗаларның яшәү, кунаклар кабул итү, дини ритуал үткәрү, "шигъри-музыкаль" кичәләр үткәрү урыны булып та хезмәт иткән. Ул "шигъри-музыкаль" кичәләрдә җыелган халыкка озын төннәр буена әкиятләр сөйләнгән, җырлар җырланган, поэмалар көйләп укылган. "Мәүлид китабы"н укыган вакытта башкаручы белән тыңлаучылар арасындагы бәйләнеш әсәрне бәян итү барышында урнашкан, китапны укучы һәм тыңлаучыларның бар игътибары әсәрнең эчтәлегенә юнәлтелгән булган. Башкаручы тыңлаучылар белән әсәр аша аралашкан.

Вәгазьләр, Коръәнне кычкырып уку, шигъри декламация, шигъри көйләүләр махсус әзерләнгән "сәхнә мәйданчыкларында" башкарылалар, мондый бәйрәм максатлары өчен өйләрне җыештырып бизиләр, көзгеләр алып куела, "бәян итүче"гә махсус урын - өй түре әзерләнә, "Аллаһ нуры" иңсен өчен, бәйрәм өстәлен ачу йоласы, дисбеләр, катнашучыларның бәйрәмчә киемнәре, бәйрәм алды намазы - болар барысы да бәйрәм үткәрү урыны турында хәбәр итәләр.

Шул рәвешчә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууы дигән анык бер вакыйга бар халыкка югары илһам бирә торган сәбәпкә әйләнә, анда катнашучылар эстетик ләззәт алуның югары дәрәҗәсен тою мөмкинлегенә ия булалар.

**Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,**
**фәлсәфә фәннәре кандидаты,**
**Татарстанның атказанган**
**сәнгать эшлеклесе**

# "Исәнме-саумы, күршекәем!"

**Күпчелегебез һәр иртәне күршеләре белән шушы сүзләрне әйтеп, исәнләшеп каршылый. Кайчагында алар белән мөнәсәбәт, еракта яшәүче туганнарга караганда, күпкә җылырак була. Кем ничек уйлыйдыр, яхшы мөнәсәбәт күңелне күтәрә, дини тәрбия сәламәтлеккә уңай йогынты ясый, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга ярдәм итә, минемчә. Юкка гына халык: "Йорт өчен җир сайлаганчы, күршеңне сайла", – димәгәндер.**




Менә безнең күршебездә шундый кешеләр яшәве бик куанычлы. Мамадыш районы, Уразбахты авылында яшәүче күрешебез Шакировлар гаиләсе күпләргә үрнәк. 2011 елның 12 августында Уразбахты авылы халкы зур югалту кичерде: егерме ел буе имам-хатыйб булып эшләүче Зиннур хәзрәт Шакиров вафат булды. Аллаһы Тәгалә кушканча яшәү рөхсәт ителмәгән, дин тотучылар гаять авыр шартларга куелган елларда дөньяга килеп, гомер юлында яшәү, имам булып эшләү мисалы, киңкырлы эшчәнлеге чыннан да үзе бер галәм, үзе бер дәвер. Җөмһүриятебездә динебез үсеш кичергән чорда Зиннур хәзрәт, мәхәллә халкы белән бергәләп, Аллаһ йортын төзергә алына. Килеп туган авырлыкларга карамастан, Аллаһның рәхмәте белән алар бу эшне башкарып чыгалар. 1994 елның апрелендә мәчет ачыла. Авыл өстендә күңелләргә үтеп керердәй моңлы азан тавышы яңгырый. Шул еллардан башлап Зиннур хәзрәт имам-хатыйб буларак үз халкына дини хезмәт күрсәтә башлый. Ул бу вазифасын бик яхшы үтәде, районыбызның мөхтәрәм хәзрәте иде. Хәзер имамлык эшен Рамил Шакиров алып бара. Туган авылыма кайткач, азан тавышы ишетү белән, әниемнән: "Кем шулай моңлы итеп азан әйтә?" – дип сорадым. Әнием: "Күршебез Рамил", – дип куйды. Рамил абый – үрнәк гаилә башлыгы. Шулай бервакыт аның белән әңгәмә корабыз. Ул сөйли, мин тыңлыйм: "Иртән уянып күземне ачуга ук, Аллага шөкер, бүген дә исән-сау йоклап тордым дип, күңелемнән Ходайга рәхмәт укыйм. Өстәл яныннан киткәндә исә ашарга ризыгым булганы өчен шөкер итәм. Эшкә баргaнда көннең матурлыгына сокланып, күбәләк-күбәләк булып яуган карларга карап, – әле ярый шушы гүзәллекне күрергә күзләрем, шушы карны шыгырдатып йөрергә аякларым, үземә ошаган, күңелемә якын эшем, шул эшкә йөрергә сәламәтлегем бар дип, – үз хәләл көчем белән эшләп тапкан акчам булганга сөенеп, көненә әллә ничә тапкыр Аллаһка рәхмәтләр укыйм. Аңардан зур акчалар да, затлы туннар да, кыйммәтле машиналар да сорамыйм, булганына мең кат шөкер итәм, алга таба да Аллаһ Раббыбыз ризыктан, эштән, саулыктан аермаса иде, дип телим". Менә нинди матур гаилә яши Мамадыш районының Уразбахты авылында. Җәмәгате Әлфия апа бар гомерен балаларга белем бирүгә багышлады. Ике уллары да тормышта үз урыннарын табып, оныклар белән сөендерделәр. Бүгенге көндә әниләре Сания апаны кадерләп яшиләр. Бу дини гаиләгә Аллаһы Тәгалә алга таба да саулык-сәламәтлек насыйп итсә иде. Зиннур хәзрәтнең эшен дәвам итүче Рамил абыйга да Аллаһы Тәгалә сабырлык бирсен.

***Фирая МИНГАЛИЕВА,***
***Мамадыш районы***
***Уразбахты авылы***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 3 (172) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35386.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 17 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**